ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ
**КАРАРЫ**

«Татарстан Республикасында кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 148-7 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан кертелгән «Татарстан Республикасында кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 148-7 номерлы Татарстан Республикасы законы проектын беренче укылышта кабул итәргә.

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин

Казан шәһәре
2025 елның 24 декабре
№ 495-VII ДС

Проект

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан кертелә

**«Татарстан Республикасында кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында»**

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗАКОНЫ

**1 статья**

«Татарстан Республикасында кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү турында» 2010 елның 21 гыйнварындагы 7-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2010, № 1-2; 2011, № 10 (I өлеш), № 12 (I өлеш); 2014, № 1-2, № 5; 2015, № 10 (I өлеш); 2016, № 3; Татарстан Республикасы законнары җыелмасы, 2016, № 40 (I өлеш); 2018, № 78 (I өлеш); 2019, № 19 (I өлеш); 2020, № 1 (I өлеш), № 87 (I өлеш); 2021, № 1 (I өлеш); 2022, № 83 (I өлеш); 2023, № 27 (I өлеш), № 35 (I өлеш), № 56 (I өлеш), № 81 (I өлеш); 2025, № 56 (I өлеш), № 75 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) $2^{1}$ статьяның 1 өлешенә түбәндәге эчтәлектәге 4 пунктны өстәргә:

«4) һөнәрчелек эшчәнлеге субъектлары – һөнәрчелек эшчәнлеге төрләренең Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан расланган исемлегендә каралган һөнәрчелек эшчәнлеген гамәлгә ашыручы, хезмәткәрләренең исемлек буенча уртача саны узган календарь елда биш кешедән артмаган кече һәм урта эшкуарлык субъектлары һәм индивидуаль эшкуар булмаган һәм «Һөнәри керемгә салым» махсус салым режимын кулланучы физик затлар (алга таба – махсус салым режимын кулланучы физик затлар).»;

2) 3 статьяның 3 өлешенә түбәндәге эчтәлектәге $14^{1}$ һәм $14^{2}$ пунктларны өстәргә:

«$14^{1}$) һөнәрчелек эшчәнлеге төрләре исемлеген, кече һәм урта эшкуарлык субъектларын һәм махсус салым режимын кулланучы физик затларны һөнәрчелек эшчәнлеге субъектларына кертү тәртибен һәм һөнәрчелек эшчәнлеге субъектлары реестрын алып бару тәртибен раслау;

$14^{2}$) һөнәрчелек эшчәнлеге субъектларының идентификация чаралары белән мәҗбүри маркировкаланырга тиеш булмаган хезмәт продуктлары исемлеген раслау;»;

3) 15 статьяның $4^{1}$ өлешен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«$4^{1}$. Махсус салым режимын кулланучы физик затларга мәгълүмати ярдәм

күрсәтү махсус салым режимын кулланучы физик затлар эшчәнлеген үстерү өчен кирәкле мәгълүматны, шул исәптән әлеге статьяның 3 өлешендәге 1, 6 һәм 7 пунктларында күрсәтелгән мәгълүматны, дәүләт хакимияте органнары һәм җирле үзидарә органнары тарафыннан әлеге статьяның 4 өлеше нигезендә мәгълүмат системаларында, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә кече һәм урта эшкуарлык субъектларына мәгълүмати ярдәм буенча рәсми сайтларда урнаштыру юлы белән гамәлгә ашырыла.»;

4) 20 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«20 статья. **Халык сәнгать кәсепләре өлкәсендә кече һәм урта эшкуарлык субъектларына һәм һөнәрчелек эшчәнлеге субъектларына ярдәм**

Халык сәнгать кәсепләре өлкәсендә кече һәм урта эшкуарлык субъектларына һәм һөнәрчелек эшчәнлеге субъектларына ярдәм күрсәтү Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнары тарафыннан түбәндәге рәвештә гамәлгә ашырыла:

1) халык сәнгать кәсепләрен, декоратив-гамәли сәнгатьне һәм һөнәрчелек эшчәнлеген торгызу һәм үстерү өчен уңайлы шартлар тудыру;

2) халык сәнгать кәсепләре өлкәсендә кече һәм урта эшкуарлык субъектларына һәм һөнәрчелек эшчәнлеге субъектларына, шул исәптән халык сәнгать кәсепләре һәм һөнәрләре палаталарына һәм үзәкләренә ярдәм итү инфраструктурасын барлыкка китерүче оешмалар төзү һәм аларның эшчәнлеген тәэмин итү;

3) халык сәнгать кәсепләре өлкәсендә кече һәм урта эшкуарлык субъектларын һәм һөнәрчелек эшчәнлеге субъектларын халык сәнгать кәсепләрен, декоратив-гамәли сәнгатьне һәм һөнәрчелек эшчәнлеген үстерүнең дәүләт программаларын (ярдәмче программаларын) эшләүдә һәм гамәлгә ашыруда катнашуга җәлеп итү;

4) халык сәнгать кәсепләре өлкәсендә кече һәм урта эшкуарлык субъектлары һәм һөнәрчелек эшчәнлеге субъектлары хезмәткәрләрен әзерләү, яңадан әзерләү һәм аларның квалификациясен күтәрү өлкәсендә ярдәм, финанс, мөлкәти, мәгълүмати, хокукый һәм консультация ярдәме күрсәтү;

5) халык сәнгать кәсепләре өлкәсендә кече һәм урта эшкуарлык субъектларына һәм һөнәрчелек эшчәнлеге субъектларына ярдәм итү буенча башка чараларны гамәлгә ашыру.».

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Рәисе

**«Татарстан Республикасында кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы закон проектына**

**АҢЛАТМА**

Закон проекты һөнәрчелек эшчәнлеге субъектларының статусын билгеләүгә һәм ныгытуга юнәлдерелгән.

Аларга хезмәткәрләренең исемлек буенча уртача саны узган календарь елда биш кешедән артмаган кече һәм урта эшкуарлык субъектлары;

индивидуаль эшкуар булмаган һәм «Һөнәри керемгә салым» махсус салым режимын кулланучы физик затлар керә.

Һөнәрчелек эшчәнлеген билгеләү федераль дәрәҗәдә норматив беркетелмәгән, шул ук вакытта «Россия Федерациясендә кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү турында» 209-ФЗ номерлы Федераль законның (алга таба – Федераль закон) 23 статьясындагы 1 өлеше нигезендә кече һәм урта эшкуарлык субъектларына һәм кече һәм урта эшкуарлык субъектларына ярдәм инфраструктурасын барлыкка китерүче оешмаларга ярдәм күрсәтү максатларында Россия Федерациясе субъектлары дәүләт хакимияте органнары һөнәри эшчәнлек төрләре исемлеген эшләргә һәм расларга хокуклылар.

Кече һәм урта эшкуарлык субъектлары хезмәткәрләренең аларны һөнәрчелек эшчәнлеге субъектларына кертү максатларында тәкъдим ителә торган биш кешедән торган чик саны һөнәрчелек һәм халык сәнгать кәсепләре өлкәсендәге экспертлар, Татарстан Республикасы Рәисе каршындагы Эшкуарлар хокукларын яклау буенча вәкаләтле вәкил, Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы, Татарстан Республикасы Сәүдә-сәнәгать палатасы һәм Татарстан Республикасы кече һәм урта бизнес предприятиеләре ассоциациясе вәкилләре белән консультацияләр барышында билгеләнде.

Һөнәрчелек әйберләрен җитештерү кул хезмәтеннән файдалану һәм остаһның махсус күнекмәләрен куллану белән характерлана. Хезмәткәрләрнең санын биш кешедән арттыру, кагыйдә буларак, җитештерү характерының продуктларны күпләп чыгару ягына авышуына китерә, бу һөнәрчелек эшчәнлегенең асылына каршы килә.

Шулай итеп, хезмәткәрләр санын биш кешедән артмаган дәрәҗәдә билгеләү эшчәнлекнең һөнәрчелек характерын, һөнәрчелек җитештерүенең уникальлеген саклау, һөнәрчелек хезмәтен сәнәгать җитештерүе белән алмаштыруны булдырмау өчен оптималь булып тора һәм Татарстан Республикасында кече бизнесның әлеге секторына ярдәм чараларын нәтиҗәле гамәлгә ашырырга мөмкинлек бирәчәк.

Һөнәрчелек эшчәнлеге субъектларына ярдәм чараларын гамәлгә ашыру максатларында закон проекты Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына һөнәрчелек эшчәнлеге төрләре исемлеген, кече һәм урта эшкуарлык субъектларын һәм махсус салым режимын кулланучы физик затларны һөнәрчелек эшчәнлеге субъектларына кертү тәртибен һәм һөнәрчелек эшчәнлеге субъектлары реестрын алып бару тәртибен раслау вәкаләтләрен бирә.

Моннан тыш, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2018 елның 28 апрелендәге 792-р номерлы карары белән һөнәрчелек хезмәте продукциясен идентификацияләү чаралары белән мәҗбүри маркировкалаудан азат итүнең Россия Федерациясе

субъектлары законнары белән билгеләнә торган мөмкинлеге күздә тотыла. Моңа бәйле рәвештә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының һөнәрчелек эшчәнлеге субъектларының идентификация чаралары белән мәҗбүри маркировкаланырга тиеш булмаган хезмәт продуктлары исемлеген раслау вәкаләте карала.

Закон проекты кысаларында шулай ук «Татарстан Республикасында кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү турында» 2010 елның 21 гыйнварындагы 7-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 20 статьясына, аны актуаль хәлгә китерү максатларында, кече һәм урта эшкуарлык субъектларына дәүләт ярдәме төрләрен билгели торган үзгәрешләр кертү каралган.

Тәкъдим ителә торган үзгәрешләр Татарстан Республикасында кече һәм урта эшкуарлыкның һөнәрчелек секторына ярдәм итү өчен хокукый нигез булдырырга, Татарстан халыкларының уникаль мәдәни үзенчәлеген сакларга һәм арттырырга мөмкинлек бирәчәк.

**«Татарстан Республикасында кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законын кабул итүгә бәйле рәвештә үз көчләрен югалткан дип танылырга, туктатылып торырга, үзгәрешләр кертелергә яки кабул ителергә тиешле Татарстан Республикасы законнары һәм башка норматив хокукый актлары**

**ИСЕМЛЕГЕ**

«Татарстан Республикасында кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законын кабул итү Татарстан Республикасы законнарын үз көчләрен югалткан дип тануны, туктатып торуны, үзгәрешләр кертүне яки кабул итүне таләп итми.

«Татарстан Республикасында кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законын кабул итү Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы мәсьәләләре» 2007 елның 23 июлендәге 325 номерлы карарына үзгәрешләр кертүне, шулай ук Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының:

һөнәрчелек эшчәнлеге төрләре исемлеген;

кече һәм урта эшкуарлык субъектларын һәм махсус салым режимын кулланучы физик затларны һөнәрчелек эшчәнлеге субъектларына кертү тәртибен;

һөнәрчелек эшчәнлеге субъектлары реестрын алып бару тәртибен;

һөнәрчелек эшчәнлеге субъектларының мәҗбүри рәвештә идентификация чаралары белән маркировкаланырга тиеш булмаган продуктлары исемлеген раславын таләп итә.

**«Татарстан Республикасында кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы закон проектын**

**ФИНАНС-ИКЪТИСАДЫЙ НИГЕЗЛӘҮ**

«Татарстан Республикасында кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законын кабул итү Татарстан Республикасы бюджетыннан өстәмә чыгымнар таләп итми.